Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлеге Илюткино авылы торак пункты
гражданнар җыены КАРАРЫ

«24» ноябрь 2021 ел № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Бикүле авыл җирлеге Илюткино авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Бикүле авыл җирлегенең Илюткино авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидлардан тыш, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан тыш 2022 елда 1500 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Илюткино авылы урамнарында юлны ремонтлау (таш һәм вак таш салу, сатып алу, ташу, җәю)
- Илюткино авылында буа территориясен төзекләндерү (плитәләр белән ныгыту, вак таш салу)

Халык җыенында рәислек итүче: А.М.Шакирова

Бикүле авыл җирлеге башлыгы А.М.Шакирова